| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ СПАССКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>СПАС МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**1 август 2022 ел** Болгар ш. **№ 22-2**

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының 2011 елның 6 апрелендәге 8-6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетының (2012 елның 5 апрелендәге 19-2 номерлы, 2016 елның 30 мартындагы 6-10 номерлы, 2018 елның 28 мартындагы 25-4 номерлы, №46-4 номерлы, 2020 елның 30 гыйнварындагы 13-1 номерлы) структурасына үзгәрешләр кертергә

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 37 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына, шулай ук «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 43 статьясына, Спас муниципаль районының вәкиллекле органына таянып

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының 2011 елның 06 апрелендәге 8-6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетының (2012 елның 5 апрелендәге 19-2 номерлы, 2016 елның 30 мартындагы 6-10 номерлы, 2018 елның 28 мартындагы 25-4 номерлы, №46-4 номерлы, 2020 елның 30 гыйнварындагы 13-1 номерлы) структурасына үзгәрешләр кертергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә.

1. Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе
2. Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары:
- икътисад буенча;
- инфраструктур үсеш буенча;
- социаль мәсьәләләр буенча.
3. Башкарма комитет эшләре буенча идарәче;
4. Мобилизация эше буенча башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе
5. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге;
6. Икътисад һәм фаразлау бүлеге;
7. Төзелеш һәм ТКХ бүлеге;
8. Гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге;
9. Яшьләр эшләре буенча спорт һәм туризм бүлеге;
10. Опека һәм попечительлек бүлеге;

11. Гомуми бүлек;

12. Архив секторы;

13.Баш архитектор секторы;

14.Балигъ булмаганнар эшләре һәм административ практика секторы

15.Юридик сектор;

16. Финанс-бюджет палатасы - башкарма комитетның юридик зат хокукы белән муниципаль учреждение формасындагы тармак органы;

17. Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы - башкарма комитетның юридик зат хокукы белән муниципаль учреждение формасындагы тармак органы;

18.Мәгариф бүлеге - башкарма комитетның юридик зат хокукы белән муниципаль учреждение формасындагы тармак органы;

19.Мәдәният бүлеге - башкарма комитетның юридик зат хокукы белән муниципаль учреждение формасындагы тармак органы;

2. Әлеге карар кабул ителгән вакыттан үз көченә керә.

Спас муниципаль районы башлыгы,
Советы Рәисе | Ф. В. Мөхәммәтов